# Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...

Һәркемнең яраткан укытучысы буладыр ул. Хәтта балалар өчен матур-матур әкиятләр, шигырьләр, мәзәкләр язучы апа-абыйларың да кайчандыр яраткан мәктәбе, укытучысы булган. Йә, мәктәп елларыннан ниләр хәтерли икән алар?





Мәктәп, мәктәп, синдә укып үскәч,
барасы юл ачык күренә...
Мәктәбем! Белем учагым! Синдә укып, синдә үстек, синдә белем алдык. Итагатьле, инсафлы, миһербанлы булырга да синдә өйрәндек. Гомернең иң изге мизгелләре мәктәбем белән бәйле.


Шаулап-гөрләп торган мәктәп еллары инде күптән артта калды, шулай да, ничәмә ничә еллар узуга да карамастан, беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергәндә, сине колач җәеп, ягымлы карашы белән иркәләп каршы алган беренче укытучылар никтер хәтердән җуелмый. Алар - гади дә, тыйнак та, үз әниең кебек күңелгә якын да кешеләр.



Бөтен гомерен балаларга биреп,
Таңнан төнгә янып көюче,
Күктә янган кояш сыман
Тирә-юньне нурга күмүче укытучым!



Укытучы! Изге бер сүз ул. Һәр кеше бу сүзнең мәгънәсенә төшенә.Укытучы бөтен көчен биреп яхшылыкны укучыларының күңеленә сеңдерергә тырыша, тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә.





# Мирсияпов Миндар Махмутович

***Алмаз, Нәзилә Зиннатовлар:***

Тарих фәненә кызыксыну уятучы Миндар абый булды. Аның дәресләрендә без кыймылдарга да куркып утыра идек. Ул үзе бик күп укый, бик күп белә иде. 45 минут буе бер китапка, бер дәфтәргә карамыча кызык итеп сөйли иде. Гел аның авызына гына карап тора идек. Рәхмәт сезгә барысы өчен дә.

***Гүзәлия Хөсәенова:***

Мирсияпов Миндар Махмутович, мәктәп директоры буларак, оста оештыручы, тәләпчән, принципиаль җитәкче булды. Педагогларның эшен бәяләүдә, укытуның материаль базасын ныгытуда, мәктәпнең районндагы дәрәҗәсен үстерүдә аның роле искиткеч зур булды. Тарих укытучысы буларак та Миндар Махмутович үзенең тирән белеме, тарихи вакыйгаларга һәм илдә барган үзгәрешләргә дөрес бәя бирүе, оста оратор булуы белән сокландыра.

***Мөхәммәтнур Хәбибуллин:***

1960-1961 уку елы башында мәктәпкә яшь укытучы килде. Ул Миндар абый булып чыкты. Физкультура дәресләрен оештырганда, ул үзенең бөтен тырышлыгын, осталыгын, белемнәрен нәтиҗәле итеп кулланды. Без ишетеп кенә белгән спорт уеннары дәресләрне күңелле, истәлекле итеп үткәререгә ярдәм итте. Таләпчән булса да, аның ягымлылыгы, төрле күнегүләр эшләгәндә булышлыгы безгә тырышып шөгыльләнергә нык этәргеч булды.

Мәктәптә чаңгылар җитми иде. Яшь укытучы монда да җаен тапты. Чаңгыга бер укучы бауларын бәйләп басса, икенчесе, аның биленә тотынып, чаңгыга баса иде. Нык чыныгып үсүебездә аның өлеше саллы дип саныйм.

***Сәетҗан Бәдертдинов*:**

Барҗы мәктәбенә кайткан яшь укытучы Миндар абыйның эшчәнлеге бигрәк тә күңелдә калган. Без, малайлар өчен, ул чын үрнәк булды. Армия турында хыялланучы егетләргә укытучы хәрби хәзерлек дәресләре бирде. Сугыш коралын сүтеп җыярга, төз атарга, коралны һәрвакытта да тәртиптә тотарга өйрәтте. Аның үз-үзен тотышына, пөхтәлегенә сокланып, үзебез дә аның кебек булырга омтыла идек. Соңыннан бергә эшләгән елларда да аннан үрнәк алдык.



# Тимербаева Розалина Абдулловна

***Мулланурова Тәлгать***:

Чын татарча сөйләшергә, язарга өйрәтүче **Тимербаева Розалина апа** – үзе бөек кеше. Татар теленең бөтен нечкәлекләрен, тамырын белгән, шуны балаларга җиткерә алган бердәнбер татар теле укытучысы иде ул.

***Ибраһимова Зөлфия:***

**Розалина Абдулловна** – минем иң яраткан укытучым иде. Ул, беренчедән, бик сөйкемле иде. Дәрестә утырганда, без аннан күзебезне дә алмадык. Ул бик таләпчән, шул ук вакытта укучылар хәленә керә белә торган укытучы булды.

***Нуриманова Әлфия***:

**Розалина Абдулловна** татар теле һәм әдәбиятының бөтен нечкәлекләрен аңлатып, туган телгә мәхәббәт уятты. Ул искиткеч белемле, энергияле мөгаллим иде, сәләтле укучылар белән генә түгел, йомшаграк укучылар белән дә нәтиҗәле эшли иде.

***Зиннәтова Нәзилә***:

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Тимербаева Розалина Абдулловна** үзенең тирән белеме, аһәңле тавышы белән һәр дәрестә безне таң калдыра иде. Розалина апаның һәр язучы турында матур итеп сөйләгәне бүгенгедәй күз алдымда.

***Хөсәенова Эльза***:

Газиз әнкәбездәй якын күргән
Зыялы һәм гади апага –
Сабыр, күркәм **Розалина апа,**
Бу шигырем Сезгә атала.
Сез мәхәббәт безгә уяттыгыз
Туган җиргә, туган якларга.
Сезнең дәресләрдә өйрәндек без
Газиз телебезне сакларга.

Сезнең белән бергә сокландык без
Туфаннарга, Тукай, Җәлилгә;
Чын күңелдән кавышу теләдек
Галиябану белән Хәлилгә.
Безнең сыйныф кебек усаллар да
Тынып калды сезнең каршыда.
Олыбыз да, кечебез дә, зурлап,
Баш иябез Сезгә барысы да.



# Муллахмәтова Рәсимә Сабировна

***Муллануров Тәлгать:***

**Муллахметова Рәсимә апа** безнең сыйныфта укыган барлык балаларга да икенче әни иде. Сыйныфыбыз бердәм һәм көчле иде, күп һәм төрле идек. Менә шушы төркемне җыйнап, һәрберебезнең холкын-гадәтен өйрәнеп, аңлап җитмәгәнне аңлатып, кирәк җирдә ияртеп баручыбыз булды Рәсимә апа. Укудан тыш чаралар үткәргәндә дә Рәсимә апа безнең белән бергә иде. Рәсимә апа үзе дә иң яхшы биюче һәм биюләрне сәхнәгә куючы иде.

***Яппарова Раушания:***

1975 елның 1 сентябре. Класска шулхәтле мөлаем, зәвык белән киенгән, чәчен матур һәм пөхтә итеп артка үреп өйгән класс җитәкчебез **Рәсимә апа** килеп керде. Без аны усал булыр дип көттек. Юк, усал булмады ул. Мәгънәле, киңәшле, төпле белемле, оештыру сәләте бик көчле иде аның. Балалар дип җан атучы, гаилә дип кайгыртучы, барысына да өлгерергә тырышучы Рәсимә апа - миндә рус теленә мәхәббәт уятучы да. Ул шигырьләрне шулкадәр сәнгатьле итеп укый иде, өйгә кайткач, мин, көзге каршына басып, нәкъ аныңча сөйләргә тырыша идем. Мәктәпне бетереп, уку йортына кергәч тә русча сөйләшергә аптырап тормаганбыз икән – бу Рәсимә апаның хезмәте.

***Зиннәтуллина Эльмира:***

**Рәсимә Сабировнаның** үтә дә сабыр холкына мин гомерем буе сокландым. Очарга дип талпынган канатларымны сындырмавы өчен, рус теленнән яхшы белем биргәне өчен рәхмәтле мин аңа. Мин укытучымның йөзенә кызыллык китермәскә, алга таба да яхшы укырга тырыштым.

***Әхмәтгәрәев Илфат:***

**Муллахмәтова Рәсимә** апаың ягымлы тавышы безне әкияттәге кебек сихерле иде. Ул бик җиңел һәм аңлаешлы итеп теманы аңлата белә иде. Рәсимә апа балалар белән эшли белә иде. Аның кырыенда әллә нинди шаян балалар да тынып калалар иде. Рәсимә апа – бик белемле, зиһенле, түземле, җаваплы, тырыш, шул ук вакытта таләпчән һәм гадел укытучы иде.

***Әхмәтҗанова Илсөяр:***

Әле бүген дә сокланам мин Рәсимә апага! Аның акыллы фикерләре, киңәшләре күңел китабыма башлангыч сыйныфтан ук язылып бара. Һәркайсыбызны үзгәртмичә, ничек бар, шулай аңларга тырышып, хаталарыбызны төзәтә-төзәтә, киләчәк тормышка әзерләүдә бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булды ул безнең өчен. Шушындый ихлас йөрәкле укытучыга сокланмый мөмкин түгел.



# Шакирова Рәсимә Бәхтиевна

***Любимов Николай:***

Первой моей классной руководительницей была **Расима Бахтиевна**, которая проводила меня во взрослую жизнь и была мне второй мамой.

***Сашина Надежда:***

В школе моей самой любимлй учительницей была **Расима Сабировна**. Я с радостью шла на её урок. Она была очень справедливой учительницей.

***Гарифуллина Венера:***

Минем яраткан укытучым – минем әнием **Рәсимә Бәхтигәрәй кызы Шакирова**. Мин аны әнием буларак та, укытучы буларак та хөрмәт иттем. Ул мәктәптә миңа, парта арасында утырган укучыга, укытучы булса, өйдә тормыш юлына басарга ярдәм итүче әни иде. Ул - сабыр, итагатьле, үз фәнен яхшы белүче мөгаллим. Аны балалар ярата иде. Ул алар белән уртак тел табып сөйләшә, кирәк чакта үзенең киңәшләрен бирә, шатлыкларны бүлешә иде. Ул үз эшенә бервакытта да салкын карамады, вакытын кызганмады. Хәзер дә укучылары, аның хәлен белергә дип, өенә кадәр киләләр. Ул аларны һәрвакыт ачык йөз белән каршы ала, үз балаларын озаткан кебек озатып кала.

***Әхмәтҗанова Илсөяр:***

Һәрвакытта да укытучы һөнәренә тугрылыклы булып кала белгән, сабыр, кешелекле, изге күңелле укытучым! Безне тормышның сыгылмалы юлларында сыгылмаска, давылларга бирешмәскә, иң авыр чакларда да яшәр өчен көч таба белергә өйрәттегез.

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч, я сабырлык;
Сиздермичә ярдәм иткәнсез,
Сез иң гүзәл кеше икәнсез!

# Шәйморатова Рәйсә Гомәровна



***Нуриманова Әлфия:***

Тыйнаклыгы белән аерылып торган **Рәйсә Гомәровна** безне күктәге йолдызларга кадәр алып менде. Астрономия дәресен без көтеп ала идек һәм бик теләп өйрәндек.

***Нуриманов Фәнис:***

Мин үземнең рәхмәт сүзләремне **Шәймуратова Рәйсә апага** әйтер идем. Ул безнең классны дүрттән алып, унынчыны бетергәнче җитәкләде. Рәйсә апа безнең һәрберебезгә җай табып, бергә шатланып һәм кайгырып, безнең өчен ут йотып тора иде. Мин үзем бик шаян булсам да, дәресләрне күп калдырсам да, Рәйсә апаның бер тапкыр да тавыш күтәреп кычырганы булмады. Безне шулай зур түземлек белән тормыш дигән олы юлга чыгарып җибәргәнегез өчен Сезгә зур рәхмәт!

***Дәүләтшина Алсу:***

Кичкетаң мәктәбендә мирем иң яраткан укытучым **Шәймуратова Рәйсә** апа булды. Аның шундый йомшак тавышы, баш түбәсенә җыеп куелган чәче, һәрвакыт чиста, пөхтә киемнәре соклану уята иде. Аның класстагы иң шаян малайларга да тавыш күтәргәнен хәтерләмим, бары тик яннарына килеп каш кына сикертә иде. Аның куллары, бармаклары һәрвакыт акбурга буялган булды. Дәрестән тыш ул безгә кул эшләрен өйрәтте.

***Мулланурова Гөлсәрия:***

Минем яраткан укытучым берәү генә, ул – **Рәйсә апа Шәймуратова.** Ул алгебра, физика, геометрия фәннәрен укытты, безгә тирән белем бирде. Рәйсә апа тынгысыз җанлы мөгаллимә, икенче әниебез иде. Ул безне инсафлы, намуслы итеп тәрбияләргә тырышты. Әнә шундый тынгысыз җанлы, белем офыклары чәчкән, укучыларының уңышларына сөенгән, безнең чын кеше булып үсүебез өчен аналарча кайгыртучы укытучым белән ничек горурланмыйсың инде?!

***Исламгәрәева  Алсу:***

**Рәйсә апа** – минем яраткан математика укытучым һәм класс җитәкчем булды. Ул безне үзенең сабырлыгы, тыйнаклыгы, йомшак тавышы, кешелеклелеге, белеме белән сокландырды. Рәйсә апа тынгысыз җанлы иде. Ул безне мөстәкыйльлеккә өйрәтте. Кайда гына, кайчан гына очратма, һаман безнең турыда кайгырта, сораша, үзенең киңәшләрен бирә. Ул безнең белән куана, безнең белән кайгыра.



# Галиев Замир Габделхакович

***Муллануров Тәлгать:***

**Галиев Замир абый** укыткан фәннәр буенча үзебезгә китап язарга була торгандыр. Хайваннар, кошлар һәм үсемлекләр турында алган белм белән теләсә кайсы югары уку йортына да бер шикләнүсез керергә була иде. Кошларга балдак кигереп очыру, агач ялгарга өйрәнү, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерү, тагын бик күп һөнәрләргә ия булырга өйрәтүче остаз булды Замир абый.

***Нуриманова Әлфия:***

Табигатьне яратырга, яшелчәләр, чәчәк-гөлләр үстерергә биология укытучыбыз **Замир Габделхакович Галиев** өйрәтте. Ул үз фәнен тирәнтен белә иде һәм бөтен белемен балаларга бирергә тырышты.

***Зиннәтова Нәзилә:***

Рәхмәтемнең зурысы - **Замир абыйга**! Ул безне агач ялгарга, җир казырга, җиләк-җимеш, яшелчә үстерергә өйрәтте.

***Зиннәтуллина Эльмира:***

**Замир абый** белән мамык та үстердек, алмагач та ялгадык, бер сабакта помидор һәм бәрәңге дә өлгерттек. Шулай итеп, томышыбыздагы тәүге тәҗрибәләребезне аның белән башлап җибәрдек. Мөстәкыйль булырга да өйрәтте ул безне – зур теплицаны ышанып тапшырды. Мамык үсентесн сындырган өчен дә орышмады, күземә генә карады, ул карашны мин хәзер дә онытмыйм.

***Хөснетдинова Чулпан:***

Бик зур рәхмәтне биология укытучысы, сыйныф җитәкчесе **Замир абыйга** әйтәсем килә. Замир абый безне үз мисалында хезмәт сөяргә, тырыш һәм гадел булырга, үз көченә ышанырга өйрәтте. Мәктәп яны бакчасында ул чын мәгънәсендә могҗизалар тудыра иде, аның шулай янып йөрүе укучыларына да күчте. Классыбыздагы бер укучының да аңа каршы дәшкәнен белмим мин. Замир абыйның малайларны татар биюенә өйрәткәне әле дә күз алдымда. Гомумән, Замир абыйның һәр дәресе, класс сәгате, косультациясе үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдә үтә иде. Ә үз фәнен ул җаны-тәне белән ратты һәм укучыларына шул мәхәббәтне күчерергә тырышты.



# Галиева Сания Шәеховна

***Нуриманова Әлфия:***

Дәресләрдән соң башлангыч сыйныф укучылары өчен озайтылган көн группасы бар иде. Группаның җитәкчесе **Сания Шәеховна Галиева**, безне үз канаты астына алып, дәресләрдә аңлап бетермәгән материалны кат-кат аңлата, балаларның ялын оештыра иде.

***Зиннәтова Нәзилә:***

**Сания апаның** ипләп кенә, тырыша-тырыша дәрес хәзерләткәне әле дә истә.

***Яппарова Раушания:***

Озайтылган көн группасында эшләгән **Сания апа Галиева** безне дәрес кенә хәзерләтеп калмады, башка бик күп төрле кирәкле эшләргә өйрәтте. Мәсәлән, ничек дөрес итеп теш щеткасын сайларга, ничек чәчәкләрдән матур букет ясарга...

***Ибраһимова Фәридә:***

Озайтылган көн башланыр алдыннан кечкенә генә гәүдәле, ябык кына, килешле генә киенгән, чәчен үреп, матур итеп баш өстенә өеп куйган, кулына кечкенә сумка тоткан, көләч йөзле **Сания Шәеховна** килеп керде. Сания апаның сабырлыгына, тыныч холыклы, игътибарлы, үзе әкрен генә булса да, бар нәрсәгә өлгерүенә, төгәллегенә, пөхтәлегенә хәйраннар калам. Ул бар эшне дә бик төгәл башкара иде: вакытында керә, укучыларны барлый, өй эшләрен сораша. Тәртип белән тезеп, ашарга алып бара, саф һавага алып чыгып уйнатырга да иренми. Өй эшләрен башкарганда да вакыт төгәл бүленә: авырдан үзләштерүчеләргә көчле укучылар, кече сыйныф укучыларына өлкән укучылар ярдәмгә килә. Балалар белән өстәмә эшли иде Сания апа. Дәресләр әзерләнеп бетүгә, безне Клуб сәнате көтә. Бу вакытта безне кызыклы әдәбият белән дә, кул эшләре белән дә, рәсем ясау, өстәл уеннары, уңган хуҗабикә серләре белән дә таныштырды Сания апа. Кайтып киткәндә, Сания апа барыбызны да барлый, шарфларны бәйли, сәдәфләрне каптыра**...**

# Нурмөхәммәтов Тимергали Нурмөхәммәтович



***Нуриманова Әлфия:***

Физикадан кырысрак күренсә дә, бик таләпчән **Тимергали абыебыз** укытты. Ул өйрәткән формулалар мәңге истән чыкмас, ахры.

***Яппарова Раушания:***

Тирләп-пешеп мәсьәлә чишкән физика дәресен, **Тимергали абыйның** безнең өчен тырышканын ничек онытасың!

***Ибраһимова Регина:***

Һич уйламассың, тормышта кызларга физика фәне кирәк булыр дип. Ә ул кирәк икән. Тимергали абыйның дәресләрендә алган белемнәрен миңа һәрвакыт ярдәм итеп тора. Шуңа күрә мин үземнең укытучыма бик рәхмәтле. Аның укытучы буларак таләпчәнлеге миңа, яшь белгечкә, өлге булды.

***Дасаев Равил:***

Күпме еллар узып та, инде үземнең ир уртасы булып, чәчләремә ак бәсләр кунса да, физика укытучысы – **Нурмөхәммәтов Тимергали** абыйның дәресләрен, ул биргән тирән, ныклы белем алдында баш иям.

...Югары уку йортында физикадан имтихан бирәм... Ашыкмыйча гына билетны алдым, игътибар белән укып чыктым. Шулвакыт, әйтерсең, Тимергали абый миңа билет сорауларын аңлата башлады. Үзем дә сизмәстән: “Хәзерләнмичә генә җавап бирергә буламы?” - дидем. Чал чәчле имтихан алучы, гаҗәпләнеп, сәерсенеп, аз гына көлемсерәп, ризалыгын бирде. Имтиханны бишлегә тапшырдым. Мин бик рәхмәтле, абый, сезгә. Сезнең тирән белемне үзегез генә белгән алымнар белән сеңдерә алуыгызга әле бүген дә чын күңелдән сокланам.

***Саматова Сәрия:***

Тимергали абый безне биш ел буе физика фәненнән укытты. Ул бик таләпчән иде. Без аның дәресенә бик куркып, өй эшләрен җентекләп әзерләп керә идек. Ул безне төгәл, җаваплы, мөстәкыйль булырга өйрәтте.



# Шәмсетдинова Розалия Шәмсетдиновна

***Нуриманова Әлфия:***

География укытучыбыз **Розалия апаның** сабырлыгына хәзер дә шаккатам. Бер генә мәктәп тарихында да юктыр глобус ватып, Розалия апаның файдалы казылмалары белән өйле уйнаучылар. Шуңа да карамастан, ул безне йомшак кына ачулана иде.

***Ижболдина Гүзәлия:***

Укытучы дигәч, минем күз алдыма **Абдуллина Розалия** апа килеп баса. Аның ягымлы карашы, ачык йөзе, төпле киңәше минем өчен мәңгегә онытылмаслык булды. География фәнен шулхәтле бирелеп аңлатуына таң калырлык иде. Кулындагы указка белән төртеп күрсәткән һәрбер шәһәр, елга, ил истә кала барды. Аның сөйләве дә ягымлы, матур, аңлаешлы, күңелгә ятышлы иде. Өй эшләрен дә ашкынып, яратып башкардым, контур карталарын да тырышып, төсле ручкалар белән буйый идем. Розалия апа балалар күңелен аңлаучы мөгаллимә булды. Беркайчан да юк-барга кызып китмәде, сабыр гына үзенең акыллы сүзләрен әйтә иде. Мин аның ачуланганын бер дә хәтерләмим, чөнки ул йомшак табигатьле иде. Безнең бер генә соравыбыз да җавапсыз калмады. Мин укытучыма бик рәхмәтле, биргән киңәшләре, өйрәткән эшләре, яхшылыкка омтылуы мәңге онытылмас. Бүген дә ул хәлләрне сорап, кызыксынып тора, аның ихлас елмаюы күңелләргә җылылык бирә.

***Зиннәтова Нәзилә:***

Үзенең нәфис гәүдәсе, тыйнаклыгы, төгәллеге белән безнең күңелләрдә урын алган география укытучысы **Шамсутдинова Розалия Шамсутдиновна**. Без Розалия апа дәресләрендә нинди генә илләргә барып кайтмадык. Без дәресләрдән соң бу кабинетта качышлы уйнап ята идек. Өйле дә уйнарга ярата идек, аның файдалы казылмаларын конфет, печенье итеп уйный-уйный бутап бетерә идек. Мәктәпнең бердәнбер зур глобус яручы да мин идем! Барысына түзгәнегез өчен рәхмәт сезгә!

***Ибраһимов Фәрит:***

Безнең класс җитәкчебез **Шамсутдинова Розалия апа** иде. Ул безгә глобустан һәм картадан илләрне, океан-диңгезләрне, елга-күлләрне табарга өйрәтте.



# Гатина
# Роза
# Зияевна

***Нуриманова Әлфия:***

Салагыш белән араны химия укытучыбыз **Роза Зияевна** атна саен яңартып торды. Кичкетаң балаларын гына укытып калмыйча, дәресләрдән соң Салагышка барып та укыта иде ул. Кыш көннәрендә ике авыл арасына чаңгы юлын салдым, ә язын, боз кузгалганда, бер боздан икенчесенә сикереп, Иж елгасын чыктым, дип сөйләгәне хәтердә. Олы яшьтә булуына карамастан, аның энергиясенә, белеменә, хәтеренә сокланып туя алмый идек.

***Нуретдинова Алсу:***

**Гатина Роза апа** безне җирне, табигатьне яратырга, сакларга өйрәтте. Без аның белән бергәләп урман утыртырга йөрдек. Беркайчан да ул безне читтән генә күзәтеп, өйрәтеп кенә калмады, ә үзе, кулына көрәк тотып, дәртләнеп эшләп йөрде. Химия фәненә дә зур кызыксыну уятты безнең яраткан укытучыбыз.

***Зарипова Рима:***

Үзе бик гади дә, әмма бик бөек тә Шәхес, мөгалимә **Роза апа Гатинаны** иң беренче мин Барҗы мәктәбенә олимпиадага баргач күрдем. Ул вакытта Барҗы-Пельга мәктәбендә укый идем. Олимпиада биремнәрен үтәгән арада мин күземне мөлаем йөзле укытучыдан алмадым, чөнки аның күзләре тынычландыра, курку-каушау юкка чыга. Барҗы мәктәбендә укыганда, укытучым белән Казанга укучылар конференциясенә барырга әзерләнү гомерлек булып күңелемә кереп калды. Мәктәп яны участогында эшләгәндә җитез кулларына күз иярми иде. Һәрвакыт оптимист, тырыш, тынгысыз укытучыма карап соклана идем.

***Дасаев Равил:***

Химия-биология укытучысы **Роза Зияевнага** хөрмәтем аеруча зур. Бүгенге көндә мине сокландырган сыйфатлары: эшчәнлеге, хезмәт сөюе, эшсез бер генә минут та тора алмавы күз алдымнан китми. Кайларга гына бармадым, кайларда гына булмадым, Роза апа кебек бер эштән дә тарсынмаган кеше күрмәдем. Кайчан гына күрмә, ул бакчада эш белән мәшгуль иде. Аның кара балчык белән яргаланып бетән кулларыннан да матур куллар юк иде.



# Сәләхетдинова Нурзада Хәбибулловна

***Нуриманова Әлфия:***

**Нурзада Хәбибулловна Сәләхетдинова** үзенең вакытын, сәламәтлеген, тырышлыгын балалар укытуга, тәрбияләүгә кызганмавы белән хәтергә тирән уелып калды.

***Габрахманова Әлфия:***

**Нурзада Хабибулловна** безне рус теленнән укытты. Нурзада апа, бөтен көчен куеп, безгә белем бирде һәм кеше булырга ярдәм итте. Безнең тырышып укуга ул бик тә сөенә иде.

***Исламгәрәев Айдар:***

**Нурзада апа** мине рус теленнән укытты һәм класс җитәкчем булды. Төпле киңәшләре, безгә аналарча ягымлы мөнәсәбәте күңелләрдә якты эз калдырды. Ул безне мөстәкыйльлеккә өйтәтте. Кайда гына, кайчан гына очратма, һаман безнең турыда кайгырта, сораша, үзенең киңәшләрен бирә.

***Нуретдинова Алсу:***

**Салахутдинова Нурзада апа** безгә “Этика и психология семейной жизни” дигән фәннән дәрес бирде. Ул дәресләрдә Нурзада апа безне киләчәк зур тормыш юлына әзерләде, төпле киңәшләрен бирде. Нурзада Хабибулловна һәр дәресне тормыш белән бәйләп, кызыклы итеп үткәрә иде. Ә соңыннан, үзем дә укытучы булып эшли башлаган елларда, Нурзада апаның һәрвакыт ярдәмен тоеп яшәдем. Аның сәнгатьле итеп шигырь сөйләве, матур итеп көлүе әле дә күз алдымда**.**

***Саматова Сәрия:***

**Нурзада апа** безне 10 сыйныфта рус теленнән укытты. Минем күңелдә ул сабыр, төгәл, таләпчән булып калды. Аның дәресләре бик кызыклы һәм мавыктыргыч була иде.



# Валидова Фәния Ахуновна

***Нуриманова Әлфия:***

Сыйныф җитәкчеләремнән **Фәния Ахуновна Вәлидова** үзенең пөхтәлеге, төгәллеге белән истә калды.

***Зиннәтова Нәзилә:***

Безнең класс җитәкчесе рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Валидова Фәния Ахуновна** булды. Ул безнең шаянлыкларны гафу итеп, үз кызлары кебек яратты. Берәр дәрес булмаса, безгә гел рус теле куялар иде. Ахыр чиктә түзмәдек, дәрестән качтык. Апа безне эзләгән, тапмаган. Шуның өчен дәрестән соң рус теле укыдык**.** Шушы вакыйгага бик истә калды, чөнки апа безне ачуланмады. Аңа сабыр булганы өчен зур рәхмәт.

***Салахова Ләрисә:***

Минем сыйныф җитәкчесе – рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Фәния апа**. Ул - бик тырыш, уңган, булган, бик белемле мөгаллимә. Аның дәресләре бик мавыктыргыч, файдалы үтә иде. Ул бик таләпчән дә, йомшак күңелле дә, сабыр да, күркәм дә була белде. Безнең сыйныфта гел кызлар гына булды, шуңа күрә без бик дус, тату идек. Нинди генә вакытлар булмасын, без гел Фәния апа белән киңәшләшә идек. Ул һәрберебез өчен янды, көйде, икенче әниебез булды.

***Хөснетдинова Чулпан:***

Рус теле укытучысы һәм сыйныф җитәкчесе **Фәния Ахуновнага** булган рәхмәт хисләрем бик зур. Рус теленә, рус әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләүгә күп көч кертте ул. Без класста тәнәфестә дә гел рус телендә генә аралаша идек. Фәния Ахуновна шигырьләрне шундый матур итеп, кино артистлары кебек укый иде. Мәктәптә ятланган шигырьләр хәзер дә истә. Фәния апа безгә үзеңне тоту кагыйдәләрен, дуслык кадерен, ата-ана хакын, туганлык хисләренең кадерен белергә өйрәтте. Гел кызлардан торган сыйныфта ул безнең әниебез, өлкән апабыз кебек барыбызны да кайгыртып торды.



# Әхмәдиева Өмелхәер Фатыйховна

***Хөсәенова Гүзәлия:***

Өмелхәер апа – минем сыйныф җитәкчем һәм математикадан укытучым. 5-8 сыйныфларда без класста 26 бала укыдык. Классыбыз шаян-шук иде, безне “кулда тотарга” Өмелхәер апага җиңел булмагандыр. Ләкин ул үзенең сабырлыгы, тыйнаклыгы, белеме белән сокландырды. Төпле киңәшләре, безгә аналарча ягымлы мөнәсәбәте, кирәк чакта кырыс та булуы күңелләрдә якты эз калдырды. Класс җитәкчебез безне мөстәкыйльлеккә өйрәтте.

***Гатина Гөлзар:***

Нурлы йөзе, мөлаемлылыгы белән башкалардан аерылып торучы Өмелхәер апаны беренче күрүем институтны тәмамлап эшли башлаган елларда булды. Укытучыларның август киңәшмәсендә яшь математиклар аңа карап, бу сөйкемле ана кайсы мәктәпнеке микән дип сокланып сөйләштек. Кичкетаң мәктәбендә эшли башлагач, аның чынлап та күркәм ханым икәнлегенә инандым. Балалар белән һәрвакыт ягымлы, сабыр холыклы, һәр укучыга игътибарлы булуы белән безгә үрнәк идегез, Өмелхәер апа. Хисап фәне ул - тормышта иң кирәкле фән. Һәркемнең күңелендә онытылмаслык эз калдыруыгыз өчен рәхмәт сезгә.

***Әхмәтҗанова Илсөяр:***

Укытучы, мәктәп.
Бу ике сүз – йөрәгемдә яши янәшә;
Мәктәбем, дип әйткән чакта күңел,
Укытучым, дип йөрәк эндәшә.

Укытучы сүзен ишеткәч тә, минем күз алдыма кулына белем ачкычы белән китап тоткан, пөхтә итеп киенгән, мөлаем йөзле илаһи бер зат - Өмелхәер апа килеп баса. Дөньядагы барлык яхшы сыйфатларга ия булган, белем юлын, тормыш юлын күрсәтүче маягыбыз ул безнең.



# Саттарова Нәзирә Фатыйховна

***Алмаз Зиннатов:***

Безне Барҗы-Умга башлангыч мәктәбендә Хәтирә апа укытты. Хәтирә апа булмаганда, **Нәзирә апага** безне укытырга туры килде. Нәзирә апа үзенең тыйнаклыгы, тырышлыгы, төгәллеге һәм хезмәт сөючәнлеге белән минем исемдә калган. Ул үзендә булган бөтен яхшы сыйфатларны бездә тәрбияләргә тырышты. Без Башаров Айрат белән шаярсак та, ул безне кычкырып ачуланмый иде. Ул бер усал итеп кенә карый иде, без шунда ук аңлап ала идек. Нәзирә апа һәр баланы чын күңеленнән ярата белде. Минем укытучым – Нәзирә апа миңа бик якын булды, чөнки ул әле минем туганым да. Бүгенге көндә дә Нәзирә апа минем өчен яраткан укытучым, кайгыртучан туганым. Ул, күргән саен, безне хәлләр сорашып, уңышларыбызга сөенеп безнең арада яши. Рәхмәт сиңа, Нәзирә апа. Сәламәт бул, озак яшә, балаларыңның, оныкларыңның игелеген күреп яшә.

***Моратова Зәнфирә:***

Мәктәп тәмамлаганга шактый гомер узса да, кулдан тотып, язу язарга, хәреф танырга өйрәткән беренче укытучылар һич тә хәтердән чыкмый. Алар белән очрашкан саен, үзеңне һаман аларның укучысыдыр кебек хис итәсең. Һәр укучысы өчен янып-көеп йөрүче, барлык көчен куеп белем серләренә төшендерүче, һәр укучысын үз баласыдай якын күрүче, аларны тормышка чын кеше итеп әзерләүче шушы укытучылар – хөрмәткә лаек кешеләр. Аларның берсе – Барҗы-Омга башлангыч мәктәбендә укыткан **Саттарова Нәзирә апа**. Нәзирә апаның безнең өчен тырышып, һәрберебез турында әниләрчә кайгыртып йөрүе бүгенгедәй күз алдымда тора. Өченче сыйныфны бетергәнче, ул безне, чебеш анасы төсле, үз канаты астына сыендырды. Безне октябрят, аннан пионер оешмаларына кабул итте. Тырыш, белемле, ярдәмчел булырга өйрәтте ул безне. Классташларымның шактые югары белем алды, кайберләре, училище, техникум тәмамлап, тормышта үз урыннарын тапты. Шуңа күрә без аңа бик рәхмәтле. Хәзер дә без Нәзирә апаны үз анабыз кебек якын итәбез. Аңа ныклы сәламәтлек, күтәренке күңел, шатлык, бәхет телибез.



# Әхмәтҗанова Сәүдә Габделхаевна

***Зарипова Рима:***

Йөзендә балкыган нур сүнмәсен,
Күңелләрдә яшьлек уты дөрләсен.

Бу теләкләрне мин Баржы-Пельга мәктәбендә укыганда сыйныф җитәкчем булган Сәүдә апа Әхмәтҗановага телим. Сәүдә апа безне яратып, аңларга тырышып ярдәм итте. Дружина советы председателе итеп сайлангач, Сәүдә апа белән пионер тормышының барлык этапларын үтәргә туры килде. Әгерҗе пионер слетларында катнашулар күңелгә кереп калган. Ә бер елны Сәүдә апа безне Яр Чаллыга Кама буйлап экскурсиягә алып барды. Ул чактагы маҗараларны без хәзер сагынып сөйлибез. 8 сыйныфны тәмамлагач, Сәүдә апа безне Баржы мәктәбенең 9 сыйныфына үзе озата барды, чөнки укучылар өчен бик борчыла иде. Мин үземнең тормышымны педагогика белән бәйләвемдә укытучым, сыйныф җитәкчем Сәүдә апаның да өлеше бар дип уйлыйм.

***Нуриманова Әлфия:***

Тарих фәненә мәхәббәтне миндә **Сәүдә Габделхәевна** уятты. Аның сыйләвен йотлыгып тыңлый идем. Тарих укытучысы булу теләге миндә шул дәресләрдә туды.

***Ибраһимова Фәридә:***

Сәүдә Габделхаевна безне 4 нче сыйныфка, сыйныф җитәкчесе буларак каршы алды. Бу тырыш укытучы – сыйныф җитәкчебез Сәүдә апа Әхмәтҗанова, безне 10 сыйныфка кадәр үз канаты астында җил-яңгырдан саклап, тормышның агын һәм карасын аерырга өйрәтте һәм 1987 нче елның 25 июне көнне, кошчыкларын очырган кош шикелле, яшьле күзләрен сөртеп, безгә бәхет, ак юл теләп, мәктәп бусагасында басып калды.

Сәүдә апа безне беренче көннән үк бердәм коллективта яшәргә өйрәтте. Нинди генә эш эшләсәк тә, бер-беребезгә булышырга, авыр чакта ярдәм кулы сузарга кирәклеккә басым ясап торды.

Сәүдә апа безгә беренче булып немец теленең асылына, тарих фәненең әһәмиятенә төшендергән укытучы да әле ул. Аның белән үткән дәресләр әкияти бер дөньяны хәтерләтә иде. Дәрестән чыгарга чакырган кыңгырау тавышлары гына безне реаль дөньяга кайтара иде.

Сәүдә апага мин бүгенге көндә рәхмәтлемен.



# Саматова Сәвия Тимергалиевна

***Нуриманова Әлфия:***

Математикадан **Сәвия апа** укыткангa сөенеп бетә алмыйм. Бөтен белемен балаларга бирергә тырышты ул. Математикадан, геометриядән генә түгел, башка бик күп өлкәләрдән өстәмә белемнәр бирә иде ул безгә. Аның якты, матур кабинеты һәрчак гөлләргә күмелгән була иде. Үзе дә ул гөл кебек: сөйкемле, матур, тыныч укытучы иде. Хәзер дә Сәвия апа минем өчен укытучы булып кала бирә.

***Айдар Исламгараев:***

**Сәвия апа** минем математика укытучым булды. Ул безне үзенең сабырлыгы, тырышлыгы, тыйнаклыгы, кешелеклелеге, белеме белән сокландырды. Сәвия апа тынгысыз җанлы иде. Ул безне математика дөньясына алып керде.

***Марс Гатауллин:***

Кадерле, барлык хөрмәтләргә ия булган укытучым **Сәвия апа**! Сезгә үземнең рәхмәтләремне җиткерәм. Математика фәнен тирәнтен өйрәтеп, миңа шул юлдан китәргә булыштыгыз. Сезнең биргән белемегез, авыр елларымда өйгә кереп укытуларыгыз өчен мин сезгә бурычлы. Сезнең шундый сабыр, аңлаешлы итеп аңлатуларыгызга соклана идем. Сезнең ярдәм белән институтны тәмамлап киләм. Мең рәхмәт сезгә, укытучым!

***Гарифуллина Нәсимә:***

Геометриядән теорема исбатларга мине Сәвия апа өйрәтте. Җаны-тәне белән аңлаткан дәресне белми калу мөмкин түгел иде. Ә бит ул безне, теоремага нигезләнеп, тормышта үзеңнең хаклылыгыңны исбатларга өйрәткән икән.

Сәвия апа безнең класс җитәкчесе дә булды. Бала күңелен аңлый белүче, һәрчак ярдәм итәргә әзер торучы изге зат иде ул. Бергәләп дәрестән соң газеталар чыгардык, бәйрәмнәргә әзерләндек. Көн саен күрше Балтач авылыннан килеп эшләде Сәвия апа. Аның гаиләсе дә бар, берсеннән-берсе кечкенә өч кызының яраткан әниләре дә иде әле ул. Ничек җитешә алды икән дип гаҗәпләнәм хәзер. Үз сабыйларыгызга да, безгә дә күңел җылыгызны тигез бүлгәнегез өчен чын күңелдән рәхмәт сезгә, Сәвия апа!



# Ситдикова Нәкыя Нуриҗановна

***Гарифуллин Илдус:***

**Нәкыя апаның** әле яшь вакыты иде. Без аны бик тиз арада үз иттек, яраттык, чөнки ул безне математика иленә алып кереп китте. Математика дәресен мин көтеп ала идем. Нәкыя апа тыныч, сабыр булды, бервакытта да безгә тавышын күтәрмәде. Безнең сыйныфта малайлар бик шаян иде. Нәкыя апаны рәнҗеткән чаклар да булды. Шулар өчен мин Нәкыя ападан гафу үтенәм.

***Сашина Надежда:***

Нашим классным руководителем была **Ситдикова Накия Нуризяновна.** Очень добрая, отзывчивая, никогда нас не ругала. С ней весело проходили классные часы, мы ходили в походы, отмечали дни рождения класса. Каждый день Накия Нуризяновна встречала и провожала нас с улыбкой.

***Нуретдинова Алсу*:**

Бүген мин зур ихтирам белән үземнең класс җитәкчем, математика укытучысы **Ситдыйкова Нәкыя Нуриҗан** кызын искә алам. Нәкыя апа безне 5-8 классларда җитәкләде һәм математикадан укытты. Шул еллар эчендә мин аның беркайчан да безгә тавыш күтәргәнен, ачуланганын хәтерләмим. Аның тыныч, сабыр йөзе күз алдымда, йомшак тавышы колакта ишетелгән кебек. Бөтен белемен, көчен кызганмыйча, акбурга буялган куллары белән безне математика дигән авыр, ләкин кызыклы фән дөньясына алып керде. Мәктәпкә укытучы булып кайткан беренче елларымда да Нәкый апа миңа үзенең төпле киңәшләре белән гел ярдәм итеп торды.

***Зарипова Рима:***

Тормыш, яшәү серен өйрәтәсең,
Мөгалимә - гыйлем иясе.

Мәктәптә укыган еллардан башлап укытучы булып эшләү дәверендә минем янда сыйныф җитәкчем, остазым, балаларымның укытучысы **Ситдикова Нәкыя апа** булды. Сыйныф җитәкчесе буларак, аңа безнең белән җиңел булмады, чөнки ул йомшак күңелле, сабыр иде. Ачулана, усаллаша торган булмады. Гомер бик тиз үтә. Нәкыя апа минем балаларым күңелендә дә тирән белемле, сабыр, тырыш, гади мөгаллимә булып кереп калды. Үз балаларыңның игелеген, тирә-юньдәгеләрнең хөрмәтен тоеп яшә, кадерле Укытучым!



# Ситдиков Муллаян Шәехович

***Любимов Николай:***

Особая благодарность учителю машиноведения **Ситдикову М.Ш.** С этой профессией я связал всю свою жизнь  и в армии, и сейчас.

***Ибраһимова Фәридә:***

Муллаян абый Ситдиков безне 9 һәм 10 сыйныфта эксперименталь дәрес итеп алынган строительство дәресеннән укытты. Муллаян абыйның һәр дәрескә нинди дә булса үзенчәлекле яңа җиһазлар әзерләвенә без шакката идек. Строительство дәресе булгач, без цемент, ком, кирпич турында тирәнтен белергә тиеш идек.  Бу фәнне без яхшырак аңласын өчен, Муллаян абый брусоклардан вак–вак кирпичләр ясап алып килгән иде. Кирпичтән салган йортлар, корылмалар нык булсын өчен, кирпичләрне ничек салырга, цементның нинди номердагысын алып, күпме су, ком кушу серләренә төшендерде. Кирпичне дә теләсә ничек кенә салдым түгел икән шул. Аның да салу алымнары бар икән. Кызыл кирпичне салган чакта 5 рәт ложковый һәм 1 рәт тычковый салына, ә ак кирпич булганда, 3 рәт ложковый, 1 рәт тычковый.

Төзүче булмадык, ләкин ул биргән белемнәр теләсә кайсы вакытта ремонт эшләре башкарганда кирәк була. Кирпич йортлар, корылмалар яныннан үткәндә, үзем дә сизмәстән, шул тычковый һәм ложковый рәтләрен карыйм. Кирпич араларыннан коелган измәләрне күрсәм: “Муллаян абый өйрәткәнчә күләмдә цементлары кермәгән”, - дигән уйлар үтә баштан. Нәкъ Муллаян абый әйткәнчә, мәктәпкә барганда ике квартирадан торган йортлар тезелеп тора. “ Безнең дә көч керде бит бу йортларга” - дип горурланып карап үтәм шушы өйләр турыннан.

Муллаян абый Ситдиков өйрәткәнчә эшләмәгән булсак, ул да үзлектән безне өйрәтү өчен махсус әдәбиятлар укымаган булса, бу мәһабәт биналар, йортлар бүген авылыбызны бизәп тормаслар иде. Муллаян Шаехович күп кенә укучылардан тракторист–шофер ясаса, бездән төзүчеләр ясады. Аңа бүгенге көндә дә без рәхмәтлебез дип, барлык сыйныфташлар исеменнән курыкмыйча әйтә алам, чөнки алар һәркайсы да хуҗалыкларында төзүче ролен дә үтиләр.



# Гатин Азат Габдуллович

***Нуриманова Әлфия:***

Немец теле укытучыбыз **Азат Габдуллович** укучылар белән вакытын, булган белемен кызганмыйча эшләде. Төрле бәйрәмнәр, кичәләр уздыруда да Азат абый беренче булды.

***Алмаз, Нәзилә Зиннатовлар:***

Немец телен безгә Азат абый укытты. Аның дәресләрендә без диалоглар төзи идек, рәхәтләнеп җырлар җырлый идек. Дәресләр бик күңелле уза иде. Азат абый белән Гөлзар апа уздырган кичәләр аеруча күңелле уза иде. Алар үзләре дә безнең белән кичләр буе сикерә-сикерә бииләр иде. Аларда булган энергиягә без шакката идек. Бүгенге көндә дә без Азат абый һәм Гөлзар апа белән аралашып яшибез. Аларга булган хөрмәтебез бик зур.

***Саматова Люция:***

**Гатин Азат абый** безне немец теленнән укытты. Башлангыч сыйныфларда чит телләрне бөтенләй укымаган балалар өчен башка милләт телләрен өйрәнү шактый авыр иде. Латин алфавитын өйрәгәч, иң беренче немецчә җөмләне әни белән язганымны хәтерлим. Азат абый безгә телне генә өйрәтеп калмады, ул безне Германиянең халкы, мәдәнияте белән таныштырды. Без аның белән Германиядән килгән журналларны укый идек, бу безгә – чит ил күрмәгән балаларга – зур могҗиза тоелды. Шулай ук Азат абый безгә матур җырлар да өйрәтте, без хәтта алар белән Әгерҗедә фестивальдә дә катнаштык, шунда бүләк итеп бирелгән китап миндә әле һаман саклана.

Азат абый безне төгәллеккә, пөхтәлеккә өйрәтте. Аның ярдәме белән без үзебез өчен бөтенләй чит булган телне өйрәнә алдык, бу телне яраттык.

Азат абый безнең параллель классның класс җитәкчесе иде. Аның белән кздырган бәйрәмнәр: туган көннәр, Яңа ел, 8 Март һәм башкалар бик күңелле булып истә калган.



# Җиһангәрәева Рәмзия Мәсгутовна

***Гатина Гөлзар:***

Мин институтны тәмамлап эшли башлаган елларда "Яшь педагоглар слеты" оештырыла иде. Шунда вожатыйлар, организаторлар арасында бию конкурсы уздырылды. Кичкетаң мәктәбеннән Рәмзия апаның биюенә барыбыз да сокланып, беренчелекне, билгеле инде, аңа бирдек. Үзенең осталыгын балаларга да өйрәтеп, пионер эшләре белән янып-көеп эшләгән Вожатыйны хәзер дә зур ихтирам белән искә алабыз.

***Гарифуллина Нәсимә:***

Рәмзия апа гел яшь күңелле педагог булып истә калган. Мәктәптән тыш эшләрне бик оста оештыра белә иде ул. Быргы, барабан тавышлары астында үткән пионер сборлары, комсомол җыелышлары әле дә күңел түрендә якты хатирәләр булып саклана. Районда үткән фестивальләрдә сәхнәдә куйган күмәк биюләр, концерт номерлары һәрвакыт призлы урыннар яулады. Биюләргә костюм табу өчен бер дә борчылмадык, Рәмзия апабыз 1 төн эчендә үзе тегеп куя иде.

Рәмзия апаның безнең өчен тырышып, һәрберебез турында әниләрчә кайгыртып йөрүе бүгенгедәй күз алдымда тора. Ул безне, чебеш анасы төсле, үз канаты астына сыендырдырып, безне октябрят, пионер, аннан комсомол оешмаларына кабул итте. Тырыш, белемле, ярдәмчел булырга өйрәтте ул безне. Рәмзия апа безне биергә, дөрес итеп җырларга, кул эшләренә дә өйрәтте. Шуңа күрә без аңа бик рәхмәтле. Хәзер дә без Рәмзия апаны якын итәбез. Аңа ныклы сәламәтлек, күтәренке күңел, шатлык, бәхет телибез.